Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Мәлбагыш авылы №109 11 октябрь 2018 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 113 номерлы «Жир салымы турында» карарына (2015 елның 17 августындагы 140 номерлы, 2017 елның 8 августындагы 57 номерлы карарлары редакциясендә) үзгәреш кертү турында.

«Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында " 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә»

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 4нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы подпункт белән тулыландырып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 113 номерлы «Жир салымы турында" гы карарына (2015 елның 17 августындагы 140 нче номерлы, 2017 елның 8 августындагы 57 нче номерлы карарлары редакциясендә), үзгәреш кертергә:
6) «балачактан инвалидлар, инвалид балалар.»

2. Әлеге карар рәсми басма - «Маяк» газетасында басылып чыккан көннән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2015 елның 1 гыйнварыннан физик затларның жир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарны районның “Маяк” газетасында бастырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат буенча рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәренең http://aznakyevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, Финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: И.Ә.Әхтәмова